# КАРАР

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«11» ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 11 ноябрендә узган: «Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Биляр-Озеро торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, салу).
- урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Биляр-Озеро авылында парк зонасын төзеклəндерү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- товарлар сатып алу, су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;

-Биляр-Озеро авылында янгын турында хәбәр бирүче каланча сатып алу һәм урнаштырумәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 345 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 205 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 186 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 19 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Биляр-Озеро торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы

карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, салу).

- урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Биляр-Озеро авылында парк зонасын төзекләндерү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- товарлар сатып алу, су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;
- Биляр-Озеро авылында янгын турында хәбәр бирүче каланча сатып алу һәм урнаштыру мәсьәләсемәсьәләсе буенча карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.С.Оренбургов

Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы: В.С.Оренбургов